**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**дүртенче чакырылышның егерме бишенче утырышы**

**18 август ае 2023 ел** **№95** **Әбде ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегенең 2016 елның 09 июннең 20-нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегенең 2016 елның 09 июннең 20-нче номерлы карары (10.05.2017г. №31, 01.06.2017г. №32, 25.12.2017г. №52, 20.12.2018г. №105, 06.02.2019г. №108, 11.09.2019г. №117, 12.03.2021 № 15, 13.11.2021г. №54, 10.03.2022 №60, 11.01.2023г №84 карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 19 бүлектә:**

А) 5 пунктны «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

Б) 7 пунктны «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

**2) 23.1 бүлекнең 3 пунктындагы 1 пунктчасын** «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе» сүзләре белән тулыландырырга;

**3) 27.1 бүлектә:**

А) 3 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актлары» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 7 пунктта «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

в) 8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алмаштырырга;

Г) 9 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) белән» сүзләренә алмаштырырга;

Д) 10 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Әбде авыл җирлеге башлыгы: Н.Р.Рахматуллин